КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 февраль г.Казань № 75

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче; 2017 ел, 21 февраль, 111 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 951 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 858 нче; 2023 ел, 11 март, 239 нчы; 2023 ел, 5 октябрь, 1237 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 10 февраль, 75 нче карары редакциясендә)

## Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасында катнашучы адвокатларның хезмәте өчен түләү күләме

| Т/с | Түләүсез юридик ярдәм төре | Адвокатларның хезмәте өчен түләү күләме, сум |
|---|---|---|
| 1. | Хокукый консультация бирү: | |
| 1.1. | телдән | 500 |
| 1.2. | язма рәвештә | 800 |
| 2. | Түбәндәгеләрне тутыру: | |
| 2.1. | дәгъва гаризасы | 1 000 |
| 2.2. | кассация (апелляция) һәм күзәтчелек шикаятьләре | 1 000 |
| 2.3. | рәсми сораулар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар | 700 |
| 3. | Дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау | 1 100 |
| 4. | Судларда гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау | 1 500 |

Искәрмәләр:

1. Адвокатның түләүсез юридик ярдәм күрсәткән өчен хезмәте өчен түләү күләме аны күрсәтү барышында адвокат түбәндәгеләргә барган очракларда 50 процентка арттырыла:

I төркем инвалид өенә;

стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмасына;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләренә, шулай ук балигъ булмаганнарны ирегеннән мәхрүм итү урыннарына.

2. Дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, судларда гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау адвокат көн дәвамында эшнең күпме вакыт алуына карамастан йөкләмәне үтәү белән фактта шөгыльләнгән көннәр белән исәпләнә.